**Республика Татарстан**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38

тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ**

**РАЙОНЫ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38

тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» 10 2018 г. №704

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы территориясендә
шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары
буенча җайга салынулы тарифлар буенча даими
рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә
ашыруга бәйле эшләрбашкаруга киткән чыгымнарның
бер өлешен каплау максатында пассажирлар йөртүчеләргә
субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча җайга салынучы автомобиль транспортының пассажирларны һәм багаж ташуларын җайга салу һәм идарә итү системасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының билгеләнгән чикләрендә транспорт хезмәтеннән файдалануны барысы өчен дә тигез тәэмин итү максатында, Россия Федерациясенең, 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында”гы Федераль Законына, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясына, 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»

Федераль законның 14 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт курсәтүләр җитештеручеләргә - физик затларга субсидия бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында"гы № 887 Карарына, Ютазы муниципаль районы Уставына ярашлы, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен расларга (әлеге карарга кушымта №1).

2.Ютазы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.

3.Ютазы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составын расларга (әлеге карарга № 2 кушымта).

4.Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълумат чараларында бастырып чыгарырга һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С. П. Самонина

Кушымта 1

Ютазы муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына

____ 2018ел №_____

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе**

I. Субсидияләр бирүнең тәртибен һәм максатын эшләү нигезе

1.1.Әлеге Тәртип "Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы һәм Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 18 июнендәге 491 номерлы курсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субсидияләр исәбеннән барлыкка килгән Ютазы муниципаль районы бюджеты акчаларыннан агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Норматив-хокукый акты белән билгеләнгән күләмдә (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) субсидияләр бирү процедурасын һәм шартларын билгели. 2013 елның 5 апрелендәге «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүнең көндәшлекле ысуллары итеп сайлап алынган индивидуаль эшкуарларга, аларга Ютазы районы территориясендә шәһәр

һәм шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында (алга таба – Ташучы, субсидияләр

II. Субсидияләр алу хокукына ия булган юридик затлар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр категорияләре.

2.1. Субсидияләр алуга түбәндәге категория юридик затлар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр дәгъва итә ала:

• Россия Федерациясе салым органында тиешле рәвештә теркәлгән;

* 8 (сигез) кешедән артык пассажир йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль транспортында пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган затлар.

III. Субсидияләр бирү шартлары.

3.1.Субсидияләр юридик затларга – (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәт күрсәтүче индивидуаль эшкуарларга (алга таба - оешмалар) бирелә, әмма алар субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айдан соң килгән айның беренче числосына түбәндәге критерийләргә туры килергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутларда дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар җитештерүне, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелгән башкаручыны билгеләү нәтиҗәләре буенча төзелгән муниципаль маршрутларда гомуми файдаланудагы автомобиль

транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контракт булу;

* Ютазы муниципаль районы даими пассажирлар ташуның маршрут челтәре буенча пассажирлар ташу буенча хезмәт курсәтү;

* даими элемтә маршруты буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниесе нигезендә пассажирларны йөртү буенча хезмәт күрсәтү;

* Ташучының документлар белән расланган алынмый калган керемнәре барлыкка килүе;

* салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, түләнергә тиешле салымнары, җыемнары, иминият взнослары, пенялары, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычларның булмавы;

* Ютазы муниципаль районы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән кичектерелгән бурычлар һәм бюджет каршында башка бурычлар булмау;

* субсидияләр алучылар - юридик затлар үзгәртеп корылу, бетерелү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидия алучылар - шәхси эшкуарлар уз эшчәнлекләрен туктатырга тиеш түгел;

* субсидия алучылар устав капиталында чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары булырга тиеш түгел, аларның теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган дәүләт яисә территория булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше салым салуның ташламалы салым режимы бирә торган дәүләт һәм территорияләр исемлегенә кертелгән һәм (яки) финанс операцияләре (офшор зоналары) уздырганда мәгълумат ачуны һәм бирүне куздә тотмаган дәүләтләрнең һәм территорияләрнең исемлегенә кертелгән, тулаем алганда 50 проценттан артып китә;

* оешма әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан, башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә акча алырга тиеш түгел.

3.2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты Ташучы белән субсидия биру турында килешү төзи (әлеге Тәртипкә № 2 Кушымта).

## IV. Субсидияләр биру тәртибе.

4.1.Субсидия алу өчен Пассажирлар һәм багаж ташучы ай саен, отчет аеннан соң килуче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, ә декабрь аенда 20нче числога кадәр, комиссия каравына түбәндәге документларны тапшыра:

* субсидияләр бируне сорап гариза;

* әлеге тәртип буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырудан алына алмый калган керемнәрнең барлыкка килүен раслаучы исәп-хисап (Тәртипкә №1 кушымта) ;

* Ютазы муниципаль районында гомуми файдаланудагы шәһәр яны автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты карары.

4.2.Пассажирлар ташучы тарафыннан бирелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча субсидия бирүгә документларны карау комиссиясе 10 эш көне эчендә алынмыйча калган керемнәрне каплауга субсидияләр биру турында Карар кабул итә.

4.3.Килешу төзүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

- субсидия алучы тәкъдим иткән документларның әлеге Тәртипнең 4.1 пункты билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки курсәтелгән документларны тулы куләмдә тапшырмау (алып килмәү) ;

- субсидия алучы тапшырган мәгълуматның дөрес булмавы;

- Пассажирлар ташучының Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты тарафыннан расланган тарифның чик дәрәҗәсенә караганда түбәнрәк тарифларны кулланы (алга таба-тарифның чик дәрәҗәсе).

4.4. Замечаниеләр булган очракта, документлар Пассажирлар ташучыга кисәтүләрне бетерү өчен кире кайтарыла, шул ук вакытта документларны кире кайтару сәбәпләре язма рәвештә чагылдырыла.

Замечаниеләр булган очракта, Пассажирлар йөртүчегә аларны төзәтүгә бирелгән гомуми срок, документларны алган көннән соң, 3 календарь көненнән дә артмаска тиеш.

4.5. Субсидия Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының лицевой счетыннан күчерелә, алынмый калган керемнәрне каплауга субсидияләр бирү турында Карар кабул ителгәннән соң 10 (ун) эш көне эчендә.

4.6. Бирелә торган субсидия күләме билгеләнгән тәртиптә, бюджет йөкләмәләре лимитларының һәм Ютазы муниципаль районы бюджеты чыгымнарын финанслау куләмнәренең җитәрлек булмавы очрагында, киметелергә мөмкин.

4.7. Субсидия бирү, автотранспорт предприятиесен бетеру, узгәртеп кору һәм гамәлдәге Россия Федерациясе законнарында каралган башка очракларда, пассажирлар йөртүченең субсидия биру турындагы Килешудә каралган йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очрагында туктатылырга мөмкин.

## V. Алынмый калган керемнәрне кайтару суммасын исәпләү.

5.1.Муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы йөртүчедән алынмый калган керемне каплауга субсидияләр куләмен исәпләү түбәндәге формула буенча хисап юлы белән билгеләнә:

С = З-Ч

Бу очракта:

С-субсидия куләме, мең сум;

Ч – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 11 июнендәге 454 номерлы карары белән расланган транспорт чарасы классыннан (1 километр өчен 38 сум 27 тиен) һәм маршрутның

озынлыгыннан чыгып, 1 км юл үтүнең иң чик норматив узкыйммәтен исәпкә алып, автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга чыгымнар;

Д - җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар ташуның муниципаль маршрутлары буенча йөргән өчен түләүдән алынган керемнәр, мең сум.

Пассажирлар Ташучының кереме составында түбәндәге керем төрләре исәпкә алына:

• муниципаль маршрутлар вакытында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен бер тапкыр билетлар сатудан кергән табыш;

• социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның ташламалы категорияләрен йөртүгә бәйле барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан бирелә торган транспорт йөртүченең чыгымнарын компенсацияләү суммасы.

Шул ук вакытта Пассажирлар ташучының кереме транспорт чарасының 30% тан да ким булмаган тулылану күрсәткеченнән чыгып исәпләнә.

VI. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе.

6.1.Пассажирлар ташучылар бирелгән документларны тикшеру нәтиҗәләре буенча билгеләнгән алынмый калган керем суммасының нигезсез булуы ачыкланган очракта, шулай ук башка контроль чаралар уздыру нәтиҗәләре буенча субсидияләр рәвешендә билгеләнгән бюджет акчаларын кире кайтарырга тиеш.

Субсидияләрне кире кайтару Ютазы муниципаль районы бюджеты акчасыннан булеп бирелгән компенсация түләүләрен каплау өчен субсидияләр суммасы арткан очракта гамәлгә ашырыла.

6.2. Ачыкланган кагыйдә бозулар буенча комиссия тарафыннан акт төзелә һәм субсидия алучыга аңа имза куелып бирелә.

6.3. Акт алган көннән башлап, 30 календарь көннән артмаган вакыт эчендә Пассажирлар ташучы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы Башкарма комитетының шәхси счетына агымдагы финанс елында артык алынган акчаларны кире кайтарырга тиеш.

6.4. Кире кайтарылган субсидияләр суммасы Ютазы муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

6.5.Субсидияләрне кире кайтармаган очракта вәкаләтле орган кайтарылырга тиешле бюджет акчаларын суд тәртибендә кире кайтару буенча чаралар күрә.

VII. Контроль.

7.1 Вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органы оешмалар тарафыннан субсидияләрдән файдалану шартларын, максатларын һәм тәртибен утәүне тикшерәләр.

7.2. Субсидияләр биру шартларын бозу яки аларны максатчан кулланмау очраклары ачыкланган очракта, вәкаләтле органның язма таләбе буенча, акча, субсидияләр алучы тарафыннан бер ай эчендә Ютазы муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш. Әгәр субсидия билгеләнгән вакытка кайтарылмаса, ул Ютазы муниципаль районы бюджеты керемена гамәлдәге закончалыкта билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кушымта №1

Ютазы муниципаль районы территориясендә

шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары

буенча автомобиль транспорты җайга салынылучы

тарифлары буенча даими багаж һәм пассажирлар

ташуны гамәлгә ашыру белән бәйле эшләр башкаруга

чыгымнарны каплау максатларында субсидияләр биру

Тәртибенә

**Ютазы муниципаль районы муниципаль даими автобус маршрутларында пассажирлар ташуны гамәлгә ашырган затларның алынмый калган табышларын каплау суммасын**

**ИСӘПЛӘҮ** ________________________________

(автотранспорт

предприятиесе______________________________ **20__ ел**

(ай, квартал)

| Маршрут | Отчет чорында пассажирлар саны, кеше (торак пунктлар буенча) | Икътисади нигезләнгән тариф, сум | Пассажирлар ташудан алынган керемнәр, сум | | Багаж ташучылар өчен субсидия суммасы, мең сум | Капланырга тиеш булган алынмый калган табышларны каплау суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Бер юллык билетлар, сум | Айлык транспортта йөру билетлары (проездные) социальләрне дә кертеп, сум | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | |

Оешма җитәкчесе

(вәкаләтле зат) _______ _________ ________

(вазифасы) (имза) (фамилия тулысынча)

Башкаручы ______________ _____________ ________________

(вазифасы) (ФИА) (телефон)

Кушымта №2

Татарстан Республикасы

Ютазы муниципаль районы территориясендә

шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары
буенча автомобиль транспорты җайга салынылучы
тарифлары буенча даими багаж һәм пассажирлар
ташуны гамәлгә ашыру белән бәйле эшләр башкаруга
чыгымнарны каплау максатларында субсидияләр бирү
Тәртибенә

**Субсидия бирү турында**

**КИЛЕШҮ № __**

ш.т.б.Урыссу

«_____»___________2018ел.

Бер яклап, Нигезләмә буенча эш итүче Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина йөзендә ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, алга таба – "Башкарма комитет", һәм икенче яклап, ___________йөзендә, алга таба "Пассажирлар ташучы" дип аталучы, ____________нигезендә эш итүче, икесе бергә "Яклар" дип аталучы затлар, түбәндәгеләр турында килешү төзеде:

## 1. Килешү предметы

1.1.Килешү предметы булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 18 июнендәге 491 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты акчаларыннан субсидияләр бирү тора.

1.2.Субсидия күләме Пассажирлар ташучы тарафыннан бирелгән исәп-хисап һәм документлар нигезендә комиссия тарафыннан раслана.

1.3.Бирелә торган субсидияләр катгый максатчан билгеләнешкә ия һәм әлеге Килешунең 1.1 пунктында каралмаган максатларда кулланыла алмый.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1.Башкарма комитет бурычлы:

2.1.1.Субсидия бирүгә документларны карау комиссиясе әгъзалары белән берлектә (алга таба – Комиссия) әлеге килешү нигезендә тапшырылган финанс документларын тикшерергә һәм хаталар ачыкланган очракта аларны кире кайтарырга.

2.1.2.Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетыннан алынмый калган керемнәр акчасын Килешугә кул куйган көннән соң 10 (эш) эш көне эчендә Ташучы счетына күчерергә.

2.2. Башкарма комитет хокуклы:

2.2.1. Субсидия алуга Пассажирлар ташучының исәп-хисапларының бухгалтерлык исәбе мәгълуматлары буенча туры килуен тикшеруне гамәлгә ашырырга.

2.2.2.Пассажирлар йөртүче әлеге Килешу шартларын бозган очракта, Килешуне үтәүдән берьяклы тәртиптә баш тартырга, бу хакта язма рәвештә икенче якка 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

2.3. Пассажирлар Ташучы бурычлы:

2.3.1.Эшчәнлекнең субсидияләнүче төрләре буенча керемнәрне һәм чыгымнарны аерым исәпкә алып барырга.

2.3.2.Ай саен, отчет аеннан соң килуче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, ә декабрь аенда 20 числосына кадәр, комиссия каравына гамәлдәге Тәртип нигезендә субсидия алу хокукын раслаучы документлар тапшырырга:

* пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырудан алынмый калган керемнәр барлыкка килүне субсидия бирунең билгеләнгән тәртибе буенча раслый торган исәп-хисап (Тәртипкә кушымта № 1);

2.3.3.Бирелгән дөрес булмаган документлар һәм (яки) бирелгән субсидияләрне максатчан кулланмау фактын билгеләгәннән соң, 30 календарь көн эчендә алынган субсидияләрне кире кайтаруны гамәлгә ашырырга.

2.4.Пассажирлар Ташучы хокуклы:

2.4.1. Тәртипкә ярашлы һәм әлеге Килешу нигезендә субсидия алуга.

2.5.Пассажирлар ташучы Килешү буенча хокукларын киметергә юл куярга һәм уз бурычларын башкаларга кучерергә хокуклы түгел.

## 3. Исәп-хисап тәртибе

3.1. Субсидияне Пассажирлар ташучыга Башкарма комитет, Комиссия тарафыннан расланган суммада, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, Ташучының исәп-хисап счетына кучеру юлы белән түли.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1.Башкарма комитет җаваплы:

* Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты акчаларыннан субсидияләр бирү тәртибен гамәлгә ашыруда,

* исәп-хисапларны һәм документларны карау срокларын, шулай ук Пассажирлар ташучыга субсидия түләү срокларын үтәүдә.

4.2.Ташучы субсидияләр алуга тапшырылган исәп-хисапларның дөреслеге һәм максатсыз файдалану өчен җавап бирә.

4.3. Ташучының субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм кагыйдәләрен бозуы очрагында, бюджет акчалары Россия Федерациясе Бюджет законнчалыгы нигезендә җирле бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

4.4.Бирелгән субсидияне кире кайтару Башкарма комитет тарафыннан субсидияләрне кире кайтару турындагы таләпләр куелган көннән алып 30 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу срогы

5.1. Әлеге Килешү кул куйган вакыттан үз көченә керә һәм _________ кадәр гамәлдә була.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Пассажирлар ташучы Башкарма комитет һәм (яки) муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан Тәртиптә каралган тикшерүләр үткәрүгә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә ризалык белдерә.

6.2. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр язма рәвештә рәсмиләштерелгәндә һәм ике якның да тулы вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлдә була.

6.3. Яклар арасында әлеге килешү буенча яисә аның белән бәйле килеп чыккан барлык бәхәсләр һәм каршылыклар яклар арасында сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

Фикер каршылыкларын сөйләшүләр юлы белән хәл итү мөмкинлеге булмаган очракта, бәхәсләр гамәлдәге законнчалыкта билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

4.4. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелгән, алар бертигез юридик көчкә ия.

## 7. Юридические адреслар и банк реквизитлары

**Башкарма комитет**

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты

Юридик адрес: ТР, 423950,

Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., д. 38,

тел.8(85593) 2-74-16

ИНН: 1642004466

КПП: 164201001

р/с: 40204810000000000064

БИК: 049205001

Отделение - НБ Республика Татарстан

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

______________________С.П.Самонина

«____»_______________20____ел

**Пассажирлар һәм багаж ташучы**

______________/______________/

«___»_____20___ ел

Кушымта № 2

Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты карарына

__________ 2018 ел №______

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажирлар Ташучыларга субсидияләр биру комиссиясе составы**

Шәрипов Р.А. Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары – комиссия рәисе

**Комиссия әгъзалары:**

Абдуллина Е.З. - Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы

Айтыкина З.Н. – Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары,

Гыйздәтова Г.М. - "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" МБУ начальнигы (килешү буенча)

Захаров А.Н. – Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге

начальнигы

Мөхәммәтова Р.Г. – Ютазы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе